# Халкымның күңел бәйрәме

РЕПОРТАЖ

Сабан туе халкымның күңел сагышыннан арыну, пакълану, сафлану бәйрәме икәнен уйлаганыгыз бармы? Хак әгәр, шулай бу. Югыйсә, яше-карты, бала-чагасы шушы бәйрәмне көтмәс, ашкынмас иде.

Сабан туе ярминкәсеннән үк башланды бу күтәренкелек. Җыйнак, пөхтә киенгән кешеләр өере-өере белән мәшәкатьләрен кайгыртырга, табын сыен төрләндерергә, дөнья кирәген әзләштерергә дип ярминкәгә юнәлделәр. Кибет киштәләрендәге товарның бәяләре югары булуга да карамастан, сатып алучыларның куллары буш түгел иде, һәрхәлдә берсе дә нәүмиз кыяфәттә күренмәде. Бала-чага, яшь-җилкенчәк кебек тәмлетамаклар өчен почмак саен мороженый сатылу да куанычлы хәл иде. Өйләрендә күпертеп-күпертеп пешергән камыр ризыклары, тәмтом белән тулы табыннан торып килгән кешеләр дә саф һавада ярминкә коймагыннан, хуш исле кыздырмадан авыз итәр өчен чүпләмле сөлгеләр белән бизәлгән өстәл-учакларга тартылдылар. Тамак өчен түгел, күңел өчен иде бу тамаша.

Ә сабан туе көне киенгән-ясанган кешеләрнең эшлекле һәм горур кыяфәттә мәйдан буласы җиргә атлаулары белән башланды. Җәяүлеләре дә, машинада җилдерткәннәре дә, ат җигеп килүчеләре дә—һәммәсе бер булып сабан туе мәйданына юнәлделәр. Ярминкәчеләр дә яңа көнне янә ачык йөз белән каршыладылар. Кояш елмайды, мәйданның озын үләнен рәхәт җил иркәләде, бәйгене көткән тынгысыз атлар, аллы-гөлле киенгән бала-чага һәм яше-карты ыгы-зыгы килде, ә мәйдан умарта күче кебек сабыр гына гөжләде. Берәм-сәрәм адашып үткән болытлар артыннан самолет очып узды һәм аның кочагыннан җиргә—бәйрәм көткән кешеләргә атылган парашютчыларны күреп, мәйдан аһ итте. Бала-чаганың сөенечле тавышлары, җыелган халыкның соклану авазлары астында «ирекле кошлар» бер-бер артлы мәйдан түренә төшеп кунаклый тордылар. Сабан туе тамашасы әнә шулай башланып китте.

## Ир канаты ат була

Ир канаты ат була, диләр халыкта. Сабан туе программасының үзәгендә торган чараларның берсе—атлар бәйгесе. Авыл малайларының кайсы гына җилдән җитез аты белән мәйдан тирәли әйләнеп узу, бәйгедә алга чыгу турында хыялланмый икән. Ир-ат, картлар гына түгел, кызлар, карчыкларга кадәр түземсезләнеп көтәләр атлар узышын.

Иң беренче булып яшь чаптарлар чыкты көч сынашырга. Беренче парда «Чирмешән» колхозыннан «Карлыгач» (Нәфис Нигъмәтуллин) һәм «Рассвет» совхозыннан «Уран» (Айдар Бикиниев) арасында лидерлык өчен җәелде төп көрәш. Финишка «Уран» чак кына алдан килде. Җайдагы Людмила Акмурзина булган «Россия» колхозының «Красавица» кушаматлы чаптары аларның эзенә баса-баса үтте финиш сызыгын. Атына 2 генә яшь булса да, шундый җитез, киләчәге өметле аның.

Тамашачы күңелен җәлеп итәрлек атлар, гомумән, күп чыкты быел стартка. 130 дан артык ат бәйгегә чыгарга теркәлгән иде. «Рассвет» совхозы (директоры Х. Н. Атауллин), «Россия» (рәисе Ю. В. Терентьев), Хафизов исемендәге (Х. Х. Гатин) колхозлардан элекке еллардагыча ук атлар күпләп катнашты. Элек нәселле ат үрчетүгә әһәмият бирмәгән «Большевик» колхозы (В. Ф. Булатов) быел атлары белән ихтирам яулады.

Бәйге дәвам итте. Икенче группа чаптарлары арасында Кузнецов исемендәге колхоздан «Игрун» (Василий Рудин) һәм мичуринлы «Опекун» (Николай Николаев) ярышты. Финишка кадәр янәшә килделәр алар. Шулай да «Игрун» бер карыш алдарак иде.

Финиш сызыгын узуга мәйдан тоткан чаптарларны карчыклар каршылый барды. «Рассвет»тан җайдагы Ринат Вәлитов булган «Нагавица» янына да йөгереп килеп җиттеләр алар, йөгәненә бүләк элделәр. Үткән ел да 1600 метр түгәрәкне 1,51 минутта әйләнеп узган бу ат быел әлеге араны 4 секундка тизрәк урап үткән булып чыкты, яшь чаптарлар арасында беренче бүләкне яулады. Шул ук совхоздан «Боярина» (Фаяз Шәрәпов) шул ук араны 1,48 минутта үтеп икенче нәтиҗә күрсәтте. Өченче урынга Самара өлкәсенең Сергеевск районы «Липовский» совхозыннан «Заводь» (Андрей Сенин) чыкты.

60 ка якын өлкән чаптар атлар мәйдан тотты. Җиде төркемгә бүленеп ярыштылар алар. Иң көчлеләр алтынчы төркемгә туры килде. Алар «Рассвет» совхозыннан «Разбег» (җайдагы Ринат Вәлитов) һәм хуҗалыкара берләшмәдән «Раздел» (Ислам Хисамов) янәшә бәйге тотты. Һәр икесе төрле ярышларда югары күрсәткечкә ирешкән атлар.

Стартка сигнал бирүгә алар алга чыкты. Башка көндәшләре аларга каршылык күрсәтә алмады, артта калдылар. Ә ике чаптар, сөлекләр шикелле сузылып, беренче әйләнешне тәмамладылар, икенчесенә киттеләр. Ринат «Разбег»ка ирек куйды. Шуңа карамастан «Раздел» якынлаша барды. Әмма шул арада гонг чыңлады, бер-бер артлы алар финиш сызыгын үтте, «Разбег» 3200 метрны 3,31, ә «Раздел» 1 секундка калышып тәгәлләде. Чаптарлар арасенда беренче ике урынны алар бүлеште. Өченче урында «Таң»нан «Алмаз» (Ранас Шәйхетдинов) чыкты.

Сүз уңаеннан әйткәндә, мәйдан тулы тамашачы бу ике атның йомгаклау ярышында кабат узышуын көткән иде дә, кызганычка каршы, «Раздел» аңа катнаша алмады. Төп көндәше булмагач «Разбег» бу юлы җиңүне ансат яулады.

Яшь юртаклар дүртәү генә иде. Аларның да берсе түгәрәктән финишка җиткәнче чыкты. «Москва»дан «Пахтакор» (җайдагы Анатолий Савгачев), «Большевик»тан «Запасная»ны (Олег Туймешев) узып китте һәм беренчелекне яулады. «Большевик»ның икенче яшь юртагы «Прописка» (Александр Чернов) өченче бүләкне алды.

Өлкән юртаклар арасында кабат «Рассвет» вәкиле алдагы урынны алды. «Резерв» кушаматлы бу юртак (җайдагы Илдар Вәлитов) әйләнешне 2,10 минутта үтте, төсле телевизор яулады. «Большевик» колхозыннан «Приказ» кушаматлы ат (Николай Сендюков) шул ук арада нибары 0,4 секундка гына калышты. Хафизов исемендәге колхоз юртагы «Нюанс» та икенче призердан нәкъ шул кадәр, ярты секундтан да кимгә генә калышты. Бәйгенең нинди кискен барганлыгын, атлар аяклары җиргә тими узышканын, халык күңелләре белән аларны канатландырып, көч өстәп торганын гәүдәләндерде бу бәйге.

**Ат чабышларын караганда бер яклап малкайларның бар көчләренә тырышуларын күреп күңелләр нечкәрсә, икенчедән—узыштан кайткан атларның муенына сөлге-яулык бәйләүче әби-апаларны күргәч күзләргә яшь килде. 80 яшьлек бу әби үзенең сугыштан кайта алмаган улын сагынуын шулай басарга теләде микән?... Ә бу өлкән апа аклы шәлъяулыкны чаптар муенына бәйләгәч: «Ходай ризалыгы өчен булсын!»... дип догасын кем рухына багышлады соң? Ә башкалары? Мәрхүм ата-анаң, балаң, гомер юлдашың өлешен гөнаһсыз җаннарга бирү, бүләк итү нинди олы йола бит бу. Халкым йоласы.**

## Көрәш

Теләсә нинди сабан туенда көч сынашуларның иң зуры, иң мавыктыргычы—көрәш, әлбәттә. Норлат сабан туенда да шулай булды. Халыкның гадәтенә хас булганча, көрәшергә теләүчеләрнең һәммәсенә дә бу алышка катнашу мөмкинлеге бирелде. Шушы районда яшисеңме син, әллә тумышың—монда, тормышың бүтән җирдәме, яки кунакка гына килгән чит-ят кешеме—рәхим ит, мәйдан синең хәйләсез, гадел өлешеңне көтә. Чынлыкта да бил алышучылар арасында якташларыбыз белән беррәттән Урта Азия, Себер һәм башка регионнардан кайткан милләттәшләребез дә катнашты. Әмма сабан туе батыры исемен һәм призлы урыннарны үз егетләребез яуладылар! Өченче ел рәттән батыр булып калган Фәнил Гайнуллинга сабан туеның төп призы—тәкә тапшырылды. Икенче һәм өченче батырлар Фаикъ Хаҗиморатов һәм Хәлим Шәрипов махсус призларга лаек булдылар. Моннан тыш көрәшчеләрнең өчесенә дә төсле телевизор бүләк ителде.

## Капчык сугышы

Бу тамашаны карарга кеше гаҗәп күп җыелды. Карап торышка бик кызык һәм җиңел тоелса да, көндәшеңне «сугып» төшерү һәм үзеңнең утырган рәвешеңне саклап кала алу алай ансат түгел икән шул!

Моннан тыш күзне бәйләгән килеш, аяк өсте басып торган көндәшеңне егу да җиңел эш түгел икән. Күпме ир-егетләр шушы максатка ирешә алмыйча «һәлак» булдылар. Әмма бирешмәгән көчле һәм елгыр егетләр дә табылды. Күз бәйләп капчык белән сугышуда иң остасы булып Р. Сөләйманов танылды. Р. Хәбибуллин һәм Э. Гыйлалов икенче һәм өченче урыннарны бүлештеләр. Җиңүчегә бүләккә палас насыйп булды, ә соңгы икесенә люстралар бүләк иттеләр. Уенда катнашырга батырчылык иткән башкалар да сабан туе бүләкләреннән мәхрүм булмадылар.

## Чүлмәк вату

Күзен бәйләгән егет мәче кебек бик сак адымнар белән алга атлый. Чүлмәккә турылап килә бит бу, кара син! Туктады, баш очына күтәргән колгасы бер генә мизгелгә тоткарланды. Бу минутта әлеге тамашаны күзәтүче мәйдан халкы өчен шушы мизгелдән дә әһәмиятлерәк берни юк иде. Тынын алмый торган халык бер сулыштан: «Бәр!!!—дип сөрән салуга колга гөрселдәде һәм балчык чүлмәк кисәкчекләр булып тирә-якка чәчелде! «Егет икәнсең! Булдырдың!»—диештеләр. Әйтерсең ләничә йөзләгән кешенең һәркайсы шәхсән шушы минутта чүлмәкне бер сугуда юк иткән!

## Ә бу вакытта,..

**Олы мәйданның бер очында үзешчәннәр осталыкта ярышсалар, икенче кырыйда йөгерешчеләр капчык киеп узышалар иде. Аннан да ары аркан тартышу, гер күтәрү, йомырка салынган кашык кабып йөгерү** һәм башка уен төрләре буенча ярышлар дәвам итте. Мәйдан уртасындагы шома колгага да үрмәләделәр, авыш бүрәнә буйлап та йөрделәр. Кыскасы, кем нинди эшкә маһир, шул үзенең өлгерлеген күрсәтте бу көнне!

Быелгы сабан туе үзенең кунаклары белән дә бик үзенчәлекле булды. Бу көнне җирле өч телдәге гадәти сөйләмгә кушылып Германиядән килгән кунакларның: «Ахтунг! Ахтунг!»—дигән соклану һәм гаҗәпләнү катыш авазлары да еш ишетелеп торды. Татарның сабан туен үз гомерендә беренче тапкыр күргән һәм шуны үзенең илдәшләренә дә күрсәтү теләге белән янган немец кинооператорының тәэсирләренә чик-чама юк иде. Ә менә Латвиядән килгән кунаклар өчен безнең сабан туйлары инде ят нәрсә түгел иде.

«Күктән төшкән» кунакларыбыз—Казан парашютчылары да сабан туеның бер матур бизәге булдылар. Араларында хатын-кызлар да булу мәйдан халкында бигрәк тә соклану уятты. Мәйдан гөр килде. Халык уйнады, куанды, теләктәшлек белдерде, ял итте. Мәйдан бүгенге тамашадан бик тә канәгать калды. Хезмәт елы буена җыелган киеренкелек тизлеккә, өлгерлеккә, сөенечкә әверелеп мәйданга чыкты. Ял көне иде бу. Татарның милли бәйрәме көне. Кешеләр бу көнне көндәлек вак-төяк мәшәкатьләрдән өстен чыгып, чын күңелдән тантана иттеләр. Сабан туеннан таралучы әби-бабайлар телендә бер теләк туды: «Киләсе сабан туйларын да исән-имин күрергә насыйп булсын! Амин!»—диделәр алар. Күктәге алтын кояш, янәшә кырларның күтәрелеп килгән яшел дулкыны, һәм гомумән, бөтен табигать шаһит иде бу сүзләргә. Амин, кардәшләр, күрергә язсын!

Р. АЙЗАТУЛЛИН,
К. ҖАМАЛЕТДИНОВА,
Р. ШӘЙХУЛЛИНА.



Рәсемдә: җилдән җитез чаптарлар.

